| | |
|---|---|
| СОВЕТ КУГУНУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУНЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» сентябрь 2017 ел №87

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Куныр авыл җирлеге Уставының 18 статьясы, «Куныр авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 86 номерлы Куныр авыл җирлеге Советы карары, «Куныр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 12 номерлы Куныр авыл җирлеге Башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Куныр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2019 елда Куныр авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- Куныр авылында: Хабибулла Ибраһимов, Киров урамнары буенча асфальт-бетон түшәмәсен норматив хәлгә китерү, су белән тәэмин итү проектын эшләү;

- Шода авылында: Пионер урамы буенча юл ремонты, Каенсар елгасы аша күпер төзү;

- Дорга авылында: Школьная урамында юл һәм күпер ремонтлау, Школьная урамында 2 янгын гидранты урнаштыру, янгынга каршы колонкалар һәм аларга комплектлау әйберләре сатып алу;

- Улисьял авылында: Центральная урамы буенча юл ремонты;

- Кургем авылында: урам яктырткычларын алыштыру, чишмәне төзекләндерү;

- Күскем авылында: Пионер урамы буенча юл ремонты;

- Курамьял авылында урамнар яктырткычларын алыштыру, чишмәне төзекләндерү.

ЮК ӘЙЕ".

3. Куныр авыл җирлеге Советы карары нигезендә, аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җыелган акчаны экономияләү очрагында, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

4. Әлеге карарны «Хезмәт» район газетасында һәм pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар аңа имза куелган көннән үз көченә керә.

Куныр авыл җирлеге башлыгы З.Н.Әсхәдуллин